| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

9 ноябрь, 2021 ел Олы Подберезье авылы № 5

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Сосновка авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең Сосновка торак пунктында ТР Кайбыч районы, Сосновка авылы, Яр буе урамы буенча урнашкан 12-нче номерлы йорт янында 2021 елның 29 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Олы Подберезье авыл җирлеге Сосновка авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

а) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәргәндә Олы Подберезье авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) очракларын кисәтү һәм таратмау өчен профилактик, санитар-эпидемияләргә каршы чараларның үтәлешен тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районы

Олы Подберезье авыл җирлеге башлыгы О.М. Емельянова